КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 март г.Казань № 128

Казан шәһәренең Җиңү паркында сугышчы-интернационалистларга багышланган «Сугыштан соң» һәйкәлен кую турында

Һәлак булган сугышчы-интернационалистлар истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Төньяк Кавказ төбәге территориясендә коралллы конфликтларда һәм контртеррорчылык операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы координация советының Казан шәһәренең Җиңү паркында сугышчы-интернационалистларга багышланган «Сугыштан соң» һәйкәлен (алга таба – һәйкәл) кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

һәйкәлне балансста тотучыны билгеләүне;

һәйкәл урнаштыру һәм янындагы территорияне төзекләндерү эшләрен башкаруны.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин